РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-30-49; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от « 09 » ноябрь 2021 ел № 04

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын саклау максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу өчен ачык тыңлаулар үткәрү юлы белән, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урманай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының 21.04.2012 ел № 6/34 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегендә халык алдында тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында»гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.
2. Халык алдында тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Башлыгы тора.
3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2021 елның 29 ноябре 16.00 сәгатьтә;
- үткәрү урыны- Урманай авыл мәдәният йорты;
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган адрес: Урманай авылы, Татарстан урам, 15А йорт.

4. Гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең норматив хокукый актлары һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023, 2024 еллар план чорына бюджеты турында» карары проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманайы авыл җирлеге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru.).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: А.И.Закиров